КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 3 март г.Казань № 6-350

2026 елның 16 сентябреннән 18 сентябренә кадәр Казан шәһәрендә KAZAN DIGITAL WEEK – 2026 халыкара форумын әзерләүне, онлайн һәм офлайн форматларда үткәрүне тәэмин итү максатларында:

1. «Цифрлы үсешкә ярдәм ассоциациясе» коммерциягә карамаган оешмасының KAZAN DIGITAL WEEK – 2026 халыкара форумының оештыручысы (алга таба шул ук эзлеклелектә – Оештыручы, Форум) булуны һәм Форумны оештыру өчен чыгымнарны финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

2. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә һәм «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенә Форумның эшлекле программасын оештыручыларның берсе булуны йөкләргә.

3. KAZAN DIGITAL WEEK – 2026 халыкара форумын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитетын төзергә.

4. KAZAN DIGITAL WEEK – 2026 халыкара форумын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты турындагы нигезләмәне һәм аның составын (боерыкка теркәләләр) расларга.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесенә, «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» акционерлык җәмгыятенә, «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесенә, «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә, шулай ук «Республика мәгълүмат-хисаплау үзәге» акционерлык җәмгыятенә, «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына, Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясенә (төбәк эш бирүчеләр берләшмәсенә), «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыятенә, «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә, «Инностейдж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә, «БАРС Груп» акционерлык җәмгыятенә – тәэмин итүне тәкъдим итәргә: Форумны үткәрүдә оештыру ягыннан һәм техник яктан ярдәм итүне.

6. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы

министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына, «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технологик университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә, «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенә, «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесенә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә: Оештыручыга Форумны әзерләүдә һәм үткәрүдә булышлык күрсәтүне.

7. Республика башкарма хакимият органнарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарына, Форумны оештыруга һәм үткәрүгә җәлеп ителгән теләсә нинди оештыру-хокук рәвешендәге оешмаларга – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

Форумны әзерләүдә һәм үткәрүдә Оештыручыга ярдәм күрсәтүне;

әлеге боерык белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итүне.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Форумны мәгълүмати тәэмин итүне оештырырга.

9. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Форум чаралары үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен тәэмин итүдә Оештыручыга ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

10. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 3 март, б-350 нче
боерыгы белән расланды

KAZAN DIGITAL WEEK – 2026 халыкара форумын
әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. KAZAN DIGITAL WEEK – 2026 халыкара форумының оештыру комитеты (алга таба шул ук эзлеклелектә – Форум, Оештыру комитеты) федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Форумны әзерләү һәм үткәрү буенча хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән күмәк орган.

1.2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

2. Оештыру комитетының төп бурычлары

2.1. Оештыру комитетының төп бурычлары:

2.1.1. Форумны әзерләү һәм үткәрүне (Форумны әзерләү һәм үткәрү чаралары планы үтәлешен контрольдә тотуны кертеп) тәэмин итү.

2.1.2. Форумны үткәрүгә әзерләнү белән бәйле планны, программаларны һәм кайбер чараларны гамәлгә ашыру барышын анализлау, Форумны әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планының үтәлешен һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотуны тәэмин итү.

2.1.3. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру барышында федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү.

2.1.4. Форумны әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планын үтәүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр хезмәттәшлеген оештыру.

## 3. Оештыру комитетының хокуклары

3.1. Оештыру комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1.1. Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча федераль башкарма хакимият органнарыннан, республика башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә мәгълүмати материаллар соратып алырга.

3.1.2. Үз утырышларына федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен һәм башка вәкилләрен, башка кызыксынучы затларны билгеләнгән тәртиптә чакырырга.

3.1.3. Форумны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

## 4. Оештыру комитеты составы

4.1. Оештыру комитеты Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры – рәис М.И.Шадаев (килешү буенча) һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры – рәистәш А.В.Песошин җитәкчелегендә төзелә.

4.2. Оештыру комитеты рәисе:

4.2.1. Оештыру комитеты эше белән җитәкчелек итә, Оештыру комитеты утырышлары өчен мәсьәләләр исемлеген, аларны карау срокларын һәм тәртибен билгели.

4.2.2. Оештыру комитеты урынбасарлары һәм әгъзалары арасында вәкаләтләрне һәм бурычларны билгели.

4.2.3. Утырышларның көн тәртибен, аларны уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый.

4.2.4. Үзе булмаган вакыт өчен рәистәшен Оештыру комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп билгели.

4.2.5. Утырышлар беркетмәләренә һәм Оештыру комитетының башка документларына кул куя.

4.3. Оештыру комитеты әгъзалары:

4.3.1. Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша.

4.3.2. Оештыру комитеты компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга чыгара.

4.3.3. Оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

4.4. Оештыру комитеты сәркатибе:

4.4.1. Рәис яки рәистәш кушуы буенча Оештыру комитеты утырышларын үткәрүне оештыра.

4.4.2. Оештыру комитетының үткәрелгән утырышлары йомгаклары буенча беркетмәләрне рәсмиләштерә.

4.4.3. Беркетмәләрне башкаручыларга җиткерүне оештыра.

4.4.4. Оештыру комитетының үткәрелгән утырышлары йомгаклары буенча кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тотуны оештыра.

4.5. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана.

## 5. Оештыру комитеты эшчәнлеге

5.1. Оештыру комитеты:

5.1.1. Партнерларның, модераторларның, спикерларның һәм экспонентларның, тематик юнәлешләр буенча Форумның хезмәтләр җыентыгына мәкаләләр авторларының – үз илебез һәм чит илләрнең әйдәүче белгечләренең вәкиллекле кворумын төзү юлы белән Форум максатларына ирешүне тәэмин итә.

5.1.2. Федераль, республика һәм тармак массакүләм коммуникацияләр чараларында Форумның төп һәм партнерлык чараларына мәгълүмати ярдәм (күргәзмәләр, конференцияләр, кереш вебинарлар, хакатон, матбугат конференцияләре, һөнәри осталык һәм киберспорт чемпионатлары һ.б.) күрсәтүне тәэмин итә.

5.1.3. Федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм комплекслы цифрлаштыруда катнашучы оешмалар вәкилләреннән, дәүләт идарәсе, муниципаль һәм корпоратив идарә системасы җитәкчеләре һәм белгечләреннән, финанс-технологик корпорацияләр, компанияләр һәм учреждениеләрнең ИТ-бүлекчәләре директорлары һәм җитәкчеләреннән, Форумның тематик юнәлешләр кураторларыннан Форумның эшче төркемен формалаштыра.

5.1.4. Форум уздыруның түбәндәге оештыру аспектларына үзгәрешләр кертү хокукын үз өстенә ала:

төп программаны һәм кайбер чараларны үткәрү даталары һәм вакыты;

катнашучыларны теркәү һәм мәгълүмат хезмәтләренең эш графигы;

эшлекле программа структурасы һәм эчтәлеге;

тематик юнәлешләр һәм секцияләр составы;

пленар утырышның форматы һәм регламенты;

ачу һәм ябу тантаналары сценарие;

төп һәм өстәмә чаралар үткәрү урыны;

күргәзмә экспозициясе конфигурациясе;

техник визитлар маршрутлары һәм объектлары;

теркәү, катнашу һәм аккредитация шартлары;

чакырылган кунаклар, спикерлар һәм модераторлар составы.

Әлеге үзгәрешләр Форумның рәсми сайтында бастырыла һәм алар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

## 6. Оештыру комитеты утырышлары

6.1. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булуга карап, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

6.2. Утырышны рәис, аның кушуы буенча рәистәш яки урынбасарларның берсе алып бара.

Утырыш, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала. Оештыру комитеты карары, әгәр утырышта катнашучы әгъзаларның яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда рәиснең тавышы хәлиткеч була. Утырыш нәтиҗәләре буенча рәис тарафыннан имзалана торган беркетмә төзелә.

Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителә торган карарлар агымдагы эшчәнлекне гамәлгә ашырганда җитәкчелек өчен кызыксынучы федераль башкарма хакимият органнарына, республика башкарма хакимият органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, башка кызыксынучы затларга җиткерелә.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 3 март, б-350 нче
боерыгы белән расланды

KAZAN DIGITAL WEEK – 2026 халыкара форумын
әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Шадаев Мәкъсут Игоревич | Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры, оештыру комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәистәше |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Миңнеханов Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты, Цифрлы үсешкә ярдәм ассоциациясе советы рәисе, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Начвин Илья Сергеевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Габдрахманов Булат Фәнил улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары, оештыру комитеты секретаре |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдуллаҗанов Эдвард Юныс улы | «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Абдулганиева Диана Илдар кызы | Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры |

| | |
|---|---|
| | (килешү буенча) |
| Абдулхаков Айдар Камил улы | Казан шәһәренең «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча) |
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Алексеева Жанна Владимировна | Россия Федерациясе Мәдәният министры урынбасары – статс-секретарь (килешү буенча) |
| Аникин Игорь Вячеславович | «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни эшчәнлек һәм цифрлаштыру буенча проректоры урынбасары (килешү буенча) |
| Әхмәдиева Роза Шәйхәйдәр кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Аюкасов Рөстәм Анатольевич | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Вахитов Радик Рәфикъ улы | Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Власов Руслан Игоревич | «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе директоры |
| Галиев Дамир Расил улы | «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Ганиев Марат Фуат улы | «Татармультфильм» берләшмәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гарипов Ленар Наил улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары |
| Гарипов Рөстәм Рамил улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гасников Александр Владимирович | «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасы ректоры (килешү буенча) |
| Гыйльманов Рафаил Вәли улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы секретаре (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Эмиль Фидаил улы | «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Гозәеров Айдар Фаил улы | «Инностейдж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Гущин Иван Николаевич | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе |
| Давыдова Полина Михайловна | «Цифрлы транспорт һәм логистика» ассоциациясе директоры (килешү буенча) |
| Данилов Эдуард Юрьевич | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры |
| Девин Алексей Михайлович | «Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының ЗащитаИнфоТрансы» федераль дәүләт унитар предприятиесенең үсеш департаменты директоры (килешү буенча) |
| Дулат-Алеев Вадим Роберт улы | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Едельсков Алексей Евгеньевич | «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры |
| Ефремов Андрей Анатольевич | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Журавлев Антон Дмитриевич | «Россия юл фәнни-тикшеренү институты» федераль автоном учреждениесе генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Звездин Евгений Юрьевич | «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының цифрлы үсеш буенча урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Җиһаншин Азат Илдус улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |
| Зиннуров Фоат Канәфи улы | «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» югары белем бирү федераль дәүләт казна мәгариф учреждениесе башлыгы (килешү буенча) |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Казаков Юрий Михайлович | «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Кәлимуллин Ринат Рифкать улы | «Юл хәрәкәте белән автоматлаштырылган идарә итү системасы» муниципаль казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Калинин Константин Михайлович | Россия Федерациясе Хөкүмәте каршындагы Аналитик үзәк җитәкчесе (килешү буенча) |
| Карпов Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Кулешов Юрий Николаевич | «Бөтенроссия дәүләт юстиция университеты (Россия Юстиция министрлыгының Россия хокук академиясе)» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Казан институты (филиалы) директоры (килешү буенча) |
| Мәхмүтов Илнур Нәваил улы | «Россия почтасы» акционерлык җәмгыятенең «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе директоры (килешү буенча) |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миңнегалиев Роберт Хәмит улы | «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлешле чараларны үстерү һәм аларга ярдәм итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Нигъмәтҗанов Марсель Илшат улы | «Телематика» концерны генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Низамов Рәшит Корбангали улы | «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Нуриев Илшат Габделфәрт улы | «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Омельчук Андрей Владимирович | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры урынбасары (килешү буенча) |
| Пахомов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләр төбәк берләшмәсе) генераль директоры (килешү буенча) |
| Перегудов Виктор Юрьевич | Федераль юл агентлыгының Фәнни-техник тикшеренүләр һәм мәгълүмат технологияләре идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Поляков Дмитрий Владимирович | «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Прытков Евгений Александрович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының иҗтимагый тәртип саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеген оештыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Савва Арсен Владимирович | «Татарстан Республикасының Фәнни-техник мәгълүмат үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Салимов Руслан Рафаил улы | 8610 номерлы «Татарстан банкы» бүлеге идарәчесе (килешү буенча) |
| Сафин Артем Руслан улы | «Цифрлы үсешкә ярдәм ассоциациясе» коммерциягә карамаган оешмасы директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ташимов Борис Манаширович | Россия Федерациясе Транспорт министры урынбасары (килешү буенча) |
| Тимирясова Асия Витальевна | «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Трошина Елена Николаевна | Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының Цифрлаштыру һәм технологик үсеш департаменты директоры (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллина Нурания Фазыл кызы | Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсенә караган Татарстан Республикасы буенча Милли банкы – бүлеге идарәчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Хәлимов Ренат Азат улы | «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәлиуллин Нияз Андреевич | «Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Халәпов Альберт Айрат улы | «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Хәсәнов Рөстәм Шамил улы | Казан дәүләт медицина академиясе – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе филиалы директоры (килешү буенча) |
| Черников Михаил Юрьевич | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шәрифуллин Рамил Әнвәр улы | «В.М.Лебедев исемендәге Россия дәүләт гадел хөкем университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Казан филиалы директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шейкин Артем Геннадьевич | Федерация Советының Конституция законнары һәм дәүләт төзелеше комитеты рәисенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Шпак Василий Викторович | Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары (килешү буенча) |
| Эркенова Виктория Вячеславовна | «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясенең интеллектуаль транспорт системалары һәм цифрлаштыру идарәсе рәисе урынбасары (килешү буенча). |